Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шемырбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 2**

Шемырбаш авылы                                                        2022 елның 18 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шемырбаш авыл җирлеге Советының 2013 елның 16 сентябрендәге "Шемырбаш авыл җирлеге территориясендә җирләү һәм мәет күмү урыннарын карап тоту (тору) кагыйдәләре турында"гы 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 30 апрелендәге 119-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шемырбаш авыл җирлеге Уставының 32 маддәсендәге 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шемырбаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шемырбаш авыл җирлеге Советының 2013 елның 16 сентябрендәге "Шемырбаш авыл җирлеге территориясендә җирләү һәм мәет күмү урыннарын карап тоту (тору) кагыйдәләре турында"гы 7 номерлы карарының 1.4 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәп үзгәреш кертергә:

"Ватанны саклаганда һәлак булучылар күмелгән урыннар хәрби каберлекләр буларак "Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү турында" 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары карары буенча гына күчерелергә мөмкин".

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорты адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Башлыгы                                        И.Н.Сафин